| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 6 05.11.2024

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Яңа Саклау авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы: нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 15 нче ноябренә 15 сәгать 00 минутта Яңа Саклау авылы мәчете каршындагы мәйданда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
а) «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүчеләрдән тыш, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәрбер гражданнардан 1000 сум күләмендә 2024 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
1) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (брусчатка җәю)

«ӘЙЕ» “ЮК".

б) 2023 елда «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә Саклау-Баш авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 ел, №1 карары нигезендә Саклаубаш авыл җирлеге бюджетына кергән «1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (койма тоту) » гә билгеләнгән гражданнарның үзара салым акчасын төзелеш материалларына бәяләр үзгәрү сәбәпле түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә файдаланырга, шуңа бәйле рәвештә түбәндәге максатларга җибәрергә:

- 1) традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зияратка перфоратор һәм генератор сатып алу) ?

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы Л.М.Габидуллина